Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең
Иске Суркино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
карары

08 ноябрь 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2024 елның 08 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта, 2024 елның 08 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта, 2024 елның 08 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта, 2024 елның 08 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге Иске Суркино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр яшәүчедән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (материаллар сатып алу һәм суүткәргечләрне ремонтлау) тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 534 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 268 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 268 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Иске Суркино авылында гражданнар җыенын узган дип таныурга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге Иске Суркино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (материаллар сатып алу һәм суүткәргечләрне ремонтлау) тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Иске Суркино авылы, Үзәк урамы, 77 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Суркино авыл җирлеге башлыгы Н.В. Леонтьев